КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.09.2024 Казан шәһәре № 457-П

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Тарлаша Зираты» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен һәм аннан файдалануның махсус режимын раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль закон, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 12 нче июлендәге 565 нче номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Расларга:

әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Тарлаша Зираты» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел);

әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Тарлаша Зираты» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалануның махсус режимын.

2. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә, күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
18 нче  сентябрендәге 457-П
номерлы боерыгына
караган 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында урнашкан «Тарлаша Зираты» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән
**файдалануның махсус режимы**

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы 2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә (алга таба – 73-ФЗ номерлы Федераль закон), 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын, урманнардан файдалану һәм башка төрле эшләр, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин иткән очракта башкарылырга мөмкин.

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан су объектыннан яисә аның өлешеннән файдалануның махсус режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә уздыруын тәэмин итү шарты белән Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.

**1. Рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә, һәйкәлне өйрәнү эшләрен, археологик предметларны эзләү һәм алып китү максатын күздә тоткан эшләрне башкару;

73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы статьясында күрсәтелгән урманнардан файдалану һәм ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендәге башка эшләр, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен, урманнардан файдалану эшләрен һәм һәйкәл территориясе чикләрендәге башка эшләрне, яисә һәйкәлнең сакланышын тәэмин итү проектларын, йә планнаштырылган коткару проектлары нигезендә археологик кыр эшләрен үткәрү, һәйкәлнең сакланышын тәэмин итү, һәйкәлне саклап калу эшләрен башкару;

гражданнарның археологик мирас объектына керүләрен законнар нигезендә оештыру.

**2. Тыела:**

ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан

файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турындагы, яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, йә башкарыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне кертә торган коткару археологик кыр эшләрен башкару буенча эшләр башкару, проект, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен вәкаләтле орган белән килештерелгән төп бүлекләрне гамәлгә ашырмыйча башкару.